**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«21» май, 2019 ел Яр Чаллы № 1898

Җир кишәрлегенә, йорт биләүгә, гаилә составы турында, яшәү урыныннан белешмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентны раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 санлы карары, Башкарма комитетның 2018 елның 6 августындагы «ТР Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 3794 санлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җир кишәрлегенә, йорт биләүгә, гаилә составы турында, яшәү урыныннан белешмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны расларга.
2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г.Авзалов